КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 август г.Казань № 955

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәне һәм «Татарстан Республикасының Төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасында катнашучыларның мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын раслау хакында» 2016 ел, 31 декабрь, 1086 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәне һәм «Татарстан Республикасының Төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасында катнашучыларның мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын раслау хакында» 2016 ел, 31 декабрь, 1086 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының Төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәдә:

4.2 пунктның «а» пунктчасындагы җиденче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

7.8 пунктта «атасының исеме» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының Төзелеш комплексы» дәүләт мәгълүмат системасында катнашучыларның мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентында:

1.2 пунктның дүртенче – алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата гомуми таләпләрне раслау, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 июнендәге 1087 номерлы карарына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2021 елның 1 декабрендәге 2161 номерлы карары;

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Объектны төзүгә рөхсәтнамә формасын һәм файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә формасын раслау турында» 2022 елның 3 июнендәге 446/пр номерлы боерыгы;»;

1.3 пунктта:

тугызынчы абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт заказы агентлыгы» акционерлык җәмгыяте (алга таба – Агентлык)»;»;

1.3.2 пунктчада «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының» сүзләренә алыштырырга;

1.4 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның 4.1.3 пунктчасында «һәм ТР ДТКИнең 2013 елның 4 декабрендәге 94 боерыгы белән расланган ТР ДТКИ Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламенты нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.1 пунктның беренче абзацында «ТР ДЗА ДУП» сүзләрен «Агентлык» сүзенә алмаштырырга;

6.6 пунктта:

беренче абзацта «ТР ДЗА ДУП» сүзләрен «Агентлык» сүзенә алмаштырырга;

6.6.1 пунктчаның беренче абзацында «ТР ДЗА ДУП» сүзләрен «Агентлык» сүзенә алмаштырырга;

6.9 пунктта «ТР ДЗА ДУП» сүзләрен «Агентлык» сүзенә алмаштырырга;

6.10 пунктта «ТР ДЗА ДУП» сүзләрен «Агентлык» сүзенә алмаштырырга;

6.11 пунктта «ТР ДЗА ДУП» сүзләрен «Агентлык» сүзенә алмаштырырга;

7.4 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының» сүзләренә алмаштырырга;

8.2 пунктның 8.2.1 пунктчасында «атасының исеме» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин